Әлки муниципаль районы
**Иске Камка авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Алькеевский муниципальный район
**исполнительный комитет Старокам -**
**кинского сельского поселения**

***422897 ,Иске Камка авылы,Үзәк урамы,1***
**Факс/тел.(84346) 73-5-24**

***422897 с. Старое Камкино***
***улица Нижняя, д. 1***

КАРАР

2019 нчы елның 7 нче июне 15№

ТР Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 нчы елның 1 нче февралендәге 1 нче номерлы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында "Карарына үзгәрешләр кертү турында

2016 нчы елның 3 нче июлендәге 373-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында" Федераль закон, территорияне планлаштыру һәм территорияләрне комплекслы һәм тотрыклы үстерүне тәэмин итү буенча документларны әзерләүне, килештерү һәм раслауны, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. ТР Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 нчы елның 1 нче февралендәге 1 нче номерлы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында "Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 1.4 п. 18 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- планлаштыру структурасының элементы-җирлек, шәһәр округы яисә муниципаль районның җирлекара территориясенең бер өлеше (квартал, микрорайон, район һәм башка шундый элементлар). Планлаштыру структурасы элементларының төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Камка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

ТР Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Ф.А.Акберов